# Рус телендә белем бирү оешмаларының рус телле укучылары өчен 2024 нче елда туган (татар) телдән дәүләт йомгаклау аттестациясен уздыру материалларының күрсәтмә варианты

# Демонстрационный вариант контрольных измерительных материалов для проведения государственной итоговой аттестации по образовательным программам основного общего образования 2024 года по родному (татарскому) языку для русскоязычных обучающихся школ с русским языком обучения

разработан федеральным государственным автономным образовательным учреждением высшего образования
«КАЗАНСКИЙ (ПРИВОЛЖСКИЙ) ФЕДЕРАЛЬНЫЙ УНИВЕРСИТЕТ»

подготовлен государственным бюджетным учреждением
«РЕСПУБЛИКАНСКИЙ ЦЕНТР МОНИТОРИНГА КАЧЕСТВА ОБРАЗОВАНИЯ»

утвержден МИНИСТЕРСТВОМ ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

# Рус телендә белем бирү мәктәпләренең рус телле укучылары өчен 2024 нче елда туган (татар) телдән дәүләт йомгаклау аттестациясе

## Эшне башкару өчен күрсәтмә

Татар теленнән төп дәүләт имтиханын тапшыру өчен, 3 сәгать 55 минут (235 минут) вакыт бирелә. Имтихан эше **33 биремне** үз эченә алган **4** бүлектән тора. **1 нче бүлектәге** 13 бирем (1 – 13 нче биремнәр) укучыларның тыңлап аңлау күнекмәләрен тикшерүгә юнәлтелгән. **2 нче бүлектәге** 7 бирем (14 – 20 нче биремнәр) укучыларның уку күнекмәләрен тикшерү максатыннан бирелә. **3 нче бүлектәге** 8 бирем (21 – 28 нче биремнәр) укучыларның лексик-грамматик күнекмәләрен тикшерүгә кайтып кала. **4 нче бүлектәге** 29 – 32 нче биремнәр сөйләм ситуациясенә караган татарча репликалар язуны күздә тота. Ачык типтагы **33 нче бирем** укучыларның язма сөйләмен тикшерүгә юнәлдерелгән.

**Уңышлар телибез!**

## Инструкция по выполнению работы

Время, отведенное на выполнение заданий – 3 часа 55 минут (235 минут). Экзаменационная работа по татарскому языку состоит из четырех разделов, включающих 33 задания. **Раздел 1** (задания по аудированию) включает 13 заданий на понимание аутентичных текстов (задания 1 - 13). **Раздел 2** (задания по чтению) включает в себя 7 заданий (задания 14 - 20). **Раздел 3** (задания по лексике и грамматике) состоит из 8 заданий (задания 21 - 28). **Раздел 4** (задания по письменной речи) состоит из 4 заданий на написание реплик по предложенной коммуникативной ситуации (задания 29 – 32) и задания, в котором предлагается написать личное письмо (задание 33).

**Желаем успеха!**

## Раздел 1

***Прослушайте 7 коротких диалогов. В заданиях 1 - 7 укажите правильный вариант ответа. Вы услышите аудиозапись дважды.***

**1. Айсылу нәрсә белән кызыксына?**

1) көрәш
2) мәдәният
3) сәнгать

**2. Дуслар ял көнне нишләргә җыеналар?**

1) урамда йөрергә
2) урманга барырга
3) сәяхәт итәргә

**3. Рәшитнең кем буласы килә?**

1) төзүче
2) диңгезче
3) очучы

**4. Айсылуның дусты нәрсә белән шөгыльләнә?**

1) йөзү
2) йөгерү
3) сикерү

**5. Рәшит нәрсә турында чыгыш ясаган?**

1) татар мәкальләре
2) милли киемнәр
3) милли бәйрәмнәр

**6. Айсылу нинди кыз?**

1) ялкау
2) ярдәмчел
3) юмарт

**7. Җәйге каникулда Айсылу нишләргә тели?**

1) авылда ял итәргә
2) диңгезгә барырга
3) әйдаман булып эшләргә

***Прослушайте разговор двух друзей. Определите, какие из приведенных утверждений 8 - 13 соответствуют содержанию текста (1), а какие – не соответствуют (2). Вы услышите аудиозапись дважды.***

**8.** Дуслар булачак имтиханнар турында сөйләшәләр.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**9.** Алсу дустын туган көне белән котлый.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**10.** Алсу дустының туган көненә килә алмый.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**11.** Алсу әбисенә бүләк алмаган әле.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**12.** Алсу Саматка өстәл уены бүләк итәргә тели.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**13.** Саматка Алсуның бүләге бик ошый.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

## Раздел 2

***Прочитайте тексты в заданиях 14 - 16. После каждого текста определите правильный вариант ответа.***

**14.**

Робототехника буенча Ачык ярышларда катнашырга чакырабыз!

30 нчы мартта Казан федераль университетында робототехника буенча мәктәп укучылары өчен республикакүләм ярышлар уздырыла. Ярышларда 5-11 сыйныф укучылары катнаша ала. Ярышлар “зурлар” һәм “кечкенәләр” төркемнәренә бүлеп оештырылачак. Чараларда катнашу бушлай, теркәлү үткәрү урынында уздырыла. Төрле ярышларда җиңүчеләрне оештыручылардан дипломнар һәм кыйммәтле бүләкләр көтә.

Ярышлар сәгать 10.00 да башлана. Көтеп калабыз!

**Белдерүдә нәрсә турында әйтелә?**

1) Заманча техника белән кызыксынучылар өчен уздырылачак күргәзмә турында.

2) Робототехника белән кызыксынучыларны чарага чакыру турында.

3) Республикакүләм спорт ярышлары уздыру турында.

| | | |
|---|---|---|
| **15.** | Хөрмәтле укучылар, “Шигърият дөньясында” конкурсына рәхим итегез!<br>Мәктәптә татар теле атналыгында “Шигърият дөньясында” исемле конкурс оештырыла. Анда 5-11 нче сыйныф укучылары татарча шигырь сөйләп катнаша ала. Һәр сыйныф укучылары арасында бер җиңүче билгеләнәчәк. Чараның йомгаклау этабы 25 нче апрельдә мәктәпнең актлар залында узачак. Җиңүчеләргә дипломнар һәм танылган татар язучыларының китаплары тапшырылачак. Бәйгенең шартлары белән мәктәп сайтында танышырга була. | **Бу хәбәр нәрсә турында?**<br>1) Мәктәп укучылары арасында яшь шагыйрьләр конкурсы оештыру турында.<br>2) Шигъриятькә багышланган очрашуда катнашырга чакыру турында.<br>3) Мәктәп укучыларын шигырь сөйләү конкурсында катнашырга чакыру турында. |
| **16.** | Хәерле көн, Дамир! Хәлләрең ничек? Имтиханнарга әзерләнәсеңме?<br>Язгы каникулда без сыйныфыбыз белән Санкт-Петербургта экскурсиядә булдык. Бу шәһәрне Россиянең мәдәни башкаласы диләр, чөнки анда 200 дән артык музей, 70 тән артык театр эшли. Санкт-Петербургта истәлекле урыннар бик күп, без аларның күбесендә булдык. Безгә аеруча Сенат мәйданы ошады. Ел саен бу шәһәргә 10 миллионнан артык турист килә икән. Алар шәһәрнең матурлыгына сокланалар, тарихи урыннарда булырга яраталар. Ә син ял вакытында нәрсәләр эшләдең? Яңалыклар турында яз, синнән хат көтәм.<br>Сәлам белән дустың Рәсим. | **Электрон хатында Рәсим дустына нәрсә турында язган?**<br>1) Язгы ял вакытында башка шәһәргә баруы турында.<br>2) Ял вакытында гаиләсе белән Санкт-Петербургка баруы турында.<br>3) Санкт-Петербургның тарихы белән кызыксынуы турында. |

***Прочитайте текст. В заданиях 17 - 20 укажите правильный вариант ответа.***

**Тәрбияле бала**
(Өзек)

Тәрбияле баланың яхшы эшләре зурлар һәм кечкенәләр белән тереклек итүләрендә булыр. Мәсәлән, тәрбияле бала үзеннән кечкенәләргә бик шәфкатьле булыр, аларны кызганыр, һәрвакыт «туганым» дип кенә эндәшер, шулай ук үзеннән зурларга, бигрәк тә эти-әнисенә, үзенең тәрбиячеләренә, үзеннән олы яшьтәге кешеләрнең барысына да һәрвакыт хөрмәт күрсәтер...

Баланың тәрбияле булуы ашарга утырганда беленер. Тәрбияле бала зурлар күрсәткән урынга туры китереп утырыр. Терсәкләре белән өстәлгә таянмас, ашарга бирүләрен көтәр һәм, нәрсә бүлеп бирсәләр, шуны ашар. Аз гына кабып, яхшылап чәйнәп ашар...

Тәрбияле бала ашаганда ашыкмас, икмәк валчыкларын читкә төшермәс, ашны ашъяулыкка һәм үзенең киемнәренә түкмәс... Тәрбияле бала үзенә хәзерләп бирелгән чәйне яхшы гына утырып эчәр, икмәкне дә кадерләп кенә ашар. Аяк өстендә ашап йөргән кешенең икмәк валчыклары, җиргә төшеп, аяк белән таптала. Шуның өчен тәрбияле бала һичбер вакытта аяк өстендә ашап йөрмәс. Тәрбияле бала, аш яныннан торгач, майлы кулы белән әйбер тотмас, кулын киемнәренә сөртмәс, бәлки, яхшылап сабын белән юар. Авызын чайкар, зурлар бар вакытта, алар юынып бетергәнне көтәр, үзенә чират җиткәч юар.

Тәрбияле бала үз эшен үзе эшләр. Көндез кия торган киемнәрен урыныннан алып, пычраклары күренсә, үзе чистартыр. Әгәр дә үзенең көче җитмәслек эшләр булса, ул вакытта зурлардан үтенер...

Мондый балаларны һәркем яратыр. (*Ризаэддин Фәхреддин)*

**17.** Тәрбияле бала нәниләргә карата нинди булыр?
1) таләпчән
2) шәфкатьле
3) тырыш

**18.** Тәрбияле бала олыларга карата нинди булыр?
1) намуслы
2) эшчән
3) ихтирамлы

**19.** Ашаганда нишләргә ярамый?
1) Нәрсә бүлеп бирсәләр, шуны ашарга ярамый.
2) Ашыгырга ярамый.
3) Яхшылап чәйнәп ашарга ярамый.

**20.** Ашаганнан соң нишләргә кирәк?
1) Майлы куллар белән әйберләр тотарга кирәк.
2) Кулларны киемнәргә сөртергә кирәк.
3) Кулларны әйбәтләп юарга кирәк.

## Раздел 3

***Прочитайте текст. В заданиях 21 – 28 определите правильный вариант ответа.***

### Ашыгыч ярдәм

Айдар кошларны ярата. Кыш көннәрендә бакчадагы (21) ... җим салырга бер дә онытмый. Ә җәй көннәрендә әнисенә тавык, чебеш, каз, үрдәкләрне (22) ... булыша.

Бүген ул ишегалдында тагын ике ят кош күрде. «Әтием күркәләр алып кайтам дигән иде, шушылардыр инде», — дип (23) ... . Аның моңа кадәр бер дә күркә күргәне юк иде.

«Тик берсенең муены чабырган икән. Ашыгыч (24) ... кирәк», — дип, өйгә кереп китте. Өйдән көнбагыш мае һәм марля алып чыкты. «Хәзер (25) ... . Май белән сөртәбез дә марля белән бәйләп куябыз», — дип сөйләнде Айдар үз-үзенә. Әмма күркәләр аңа тоттырырга уйламадылар да. Айдарның килүен муеннарын сузып карап тордылар да, малай (26) ... килүгә, эре-эре атлап китеп бардылар. Ә теге чабырган кызыл муенлысы, кабарынып, «голдыр-голдыр» дип ачуланып, Айдарның (27) ... тешләп алды. Айдар кулына көнбагыш мае (28) ... . Аннан аңа марля урады. Күркә көлә иде. *(Заһирә Гомәрова)*

**21.** 1) җимлектә 2) җимлеккә 3) җимлектән

**22.** 1) карый 2) карап 3) карарга

**23.** 1) уйлады 2) уйлаган 3) уйлар

**24.** 1) булышырга 2) эш 3) ярдәм

| | | | |
|---|---|---|---|
| **25.** | 1) авырыйбыз | 2) дәвалыйбыз | 3) чакырабыз |
| **26.** | 1) зуррак | 2) ераграк | 3) якынрак |
| **27.** | 1) күзен | 2) кулын | 3) аягын |
| **28.** | 1) сөртә | 2) сөртте | 3) сөрткән |

## Раздел 4

***В заданиях 29-32 необходимо написать реплики в соответствии с заданной речевой ситуацией.***

**Сөйләм ситуациясенә туры килгән репликаларны языгыз.**

**29.** Сообщите учителю, что завтра вы участвуете в шахматном турнире.

**30.** Спросите у друга (подруги), какие профессии нравятся ему (ей) и почему.

**31.** Предложите младшей сестре сходить в воскресенье в Театр кукол.

**32.** Посоветуйте своим родителям посмотреть новый спектакль в татарском театре.

**33. Вы получили письмо от друга (подруги). Напишите ему (ей) письмо объемом не менее 60 слов, ответив на его (её) вопросы.**

**Для ответа на это задание используйте специальный бланк ответов.**

*... Мин ял көннәрендә туганнарым, дусларым белән аралашырга яратам. Без бергә саф һавада йөрибез, кайвакыт киногa яки кунакка барабыз. Алар белән без төрле яңалыклар, кызыклы хәбәрләр турында сөйләшәбез.*

*... Ә син кемнәр белән аралашырга яратасың?... Туганнарың һәм дусларың белән нәрсәләр турында сөйләшәсез? ... Алар белән кая барырга яратасыз?*

## Тыңлап аңлау биремнәре өчен текстлар

Прослушайте 7 коротких диалогов. В заданиях 1 - 7 укажите правильный вариант ответа. Вы услышите аудиозапись дважды.

**Беренче сорау. Айсылу нәрсә белән кызыксына?**
**Айсылу:** Сәлам, Рәшит!
**Рәшит**: Хәерле көн, Айсылу! Шимбә көнне дәресләрдән соң кая барасың?
**Айсылу**: Шимбә көнне театр училищесына барырга җыенам. Анда ачык ишекләр көне үткәрелә.
**Рәшит**: Сәгать ничәдә башлана?
**Айсылу**: 14.00 сәгатьтә. Без Мәдинә белән барабыз. Без икебез дә сәнгать белән кызыксынабыз. Әллә синең дә барасың киләме?
**Рәшит**: Бик теләп барыр идем, ләкин шимбә көнне ярышта катнашам. Көрәш буенча район беренчелеге була.
**Айсылу:** Ярар, сиңа уңышлар телим. Син бит һәр ярышта җиңәсең. Син – безнең чемпион, синең белән горурланабыз.
**Рәшит:** Рәхмәт, Айсылу, матур сүзләрең өчен. Ә сез – оста биючеләр. Сез дә төрле бәйгеләрдә катнашасыз. Мин дә сезнең белән горурланам.
**[2 секунд пауза]**
**Прослушайте диалог второй раз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

**Икенче сорау. Дуслар ял көнне нишләргә җыеналар?**
**Рәшит:** Айсылу, якшәмбе көнне нишләргә җыенасың?
**Айсылу**: Уйламадым әле. Саф һавада буласым килә, чөнки дәресләр күп, бию түгәрәгенә йөрим, урамга чыгарга вакыт калмый. Ә син нишләргә тәкъдим итәсең?
**Рәшит:** Әйдә, велосипедта урманга барабыз. Язын һава шундый саф, кошлар сайрый, агачлар яфрак яра. Минемчә, бу бик файдалы һәм күңелле ял булыр.
**Айсылу:** Әйе, мин синең белән килешәм. Язын табигать матурлана. Без гаиләбез белән урманда йөрергә яратабыз.
**Рәшит:** Димәк, син риза. Шулаймы? Төшке аштан соң сезнең йортыгыз янында очрашырбыз. Үзең белән су һәм ашарга нәрсә дә булса ал. Велосипедта озак йөргәч, ашыйсыбыз килер. Күл буенда утырып ашарбыз, ял итеп алырбыз.
**Айсылу:** Яхшы, аңладым, Рәшит. Синең планың миңа бик ошый. Минем велосипедта шулай еракка барганым юк әле. Гадәттә, мин урамда гына йөрим. Минем өчен бу кечкенә сәяхәт булыр. Ял көнне төшке аштан соң сәгать ничәдә очрашабыз?
**Рәшит:** Сәгать икедә сиңа уңайлы булырмы? Килер алдыннан мин сиңа шалтыратырмын.
**Айсылу:** Рәхмәт, дустым. Бүген әле чәршәмбе генә. Ялга кадәр тагын сөйләшербез. Бәлки башка дусларыбыз да безнең белән барырга теләр. Аларга да әйтербез.
**Рәшит**: Мин каршы түгел. Бергә-бергә күңеллерәк булыр.

**[2 секунд пауза]**
**Прослушайте диалог второй раз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

**Өченче сорау. Рәшитнең кем буласы килә?**
**Рәшит:** Айсылу, син берничә ел бию белән шөгыльләнәсең. Киләчәктә син биюче булырга телисеңме?
**Айсылу:** Мин биергә яратам, кечкенәдән бию белән шөгыльләнәм, ләкин биюче булырмын дип уйламыйм. Миңа башка һөнәр ошый. Бию үзем өчен бер шөгыль.
**Рәшит:** Кем булырга телисең алайса? Кайсы һөнәр сиңа күбрәк ошый? Син бит телләрне дә бик яратып өйрәнәсең, олимпиадаларда да катнашасың. Тәрҗемәче буласың киләме?
**Айсылу:** Юк, тәрҗемәче дә түгел.
**Рәшит:** Әйт инде, кем буласың килә?
**Айсылу:** Минем укытучы буласым килә. Мин туган телемне бик яратам, шуңа күрә татар теле укытучысы булырга хыялланам. Ә синең хыялың нинди? Сиңа кайсы һөнәрләр ошый?
**Рәшит:** Миңа берничә һөнәр ошый. Кечкенә чакта мин әтием кебек төзүче булырга хыялландым, аннары миңа диңгезче һөнәре ошый иде. Ә хәзер очучы булырга хыялланам.
**Айсылу:** Хыялың зур икән, дустым! Син яхшы укыйсың бит, спорт белән дә шөгыльләнәсең. Хыялың тормышка ашар дип уйлыйм.
**Рәшит:** Рәхмәт, дустым.
**[2 секунд пауза]**
**Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

**Дүртенче сорау. Айсылуның дусты нәрсә белән шөгыльләнә?**
**Рәшит:** Айсылу, сәлам, син кая ашыгасың?
**Айсылу:** Сәлам, Рәшит! Әйе, ашыгам, соңга калам. Дустым ярышта катнаша, шуны карарга барам. Әйдә, минем белән барасыңмы? Вакытың бармы?
**Рәшит:** Ярыш кайда була? Дустың нәрсә белән шөгыльләнә?
**Айсылу:** Дустым Мәдинә йөзү белән шөгыльләнә. Бүген ярыш “Оргсинтез” бассейнында була. Сәгать унбердә башлана, шуңа күрә ашыгырга кирәк. Ял көнне транспорт начар йөри бит.
**Рәшит:** Ярар, мин дә синең белән барам. Минем андый ярышларда булганым юк әле. Нинди транспорт уңайлырак булыр?
**Айсылу:** Метрода тизрәк булыр дип уйлыйм. Ярыш башланганчы барып җитәрбез. Мин дустыма киләм дип сүз бирдем. Мин соңга калсам, ул борчылыр.
**Рәшит:** Вакыт бар әле. Минемчә, без соңга калмаска тиеш. Әйдә, метро станциясенә киттек. Мәдинә күптән йөзү белән шөгыльләнәме? Ярышларда еш катнашамы?

**Айсылу:** Бишенче сыйныфтан бирле шөгыльләнә. Димәк, биш ел инде. Ул – Республика чемпионы. Мин дустым белән горурланам.
**[2 секунд пауза]**
**Прослушайте диалог второй раз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

**Бишенче сорау. Рәшит нәрсә турында чыгыш ясаган?**
**Рәшит:** Айсылу, сәлам, хәлләрең ничек?
**Айсылу:** Рәхмәт, яхшы. Кичә син ник мәктәптә булмадың?
**Рәшит:** Кичә мин укучыларның фәнни конференциясендә катнаштым.
**Айсылу:** Ул кайда булды?
**Рәшит:** 17 нче гимназиядә. Казан мәктәпләреннән дә, башка районнардан да укучылар күп иде. Безнең секциядә сигезенче һәм тугызынчы сыйныф укучылары чыгыш ясадылар. Чыгышлар бик кызыклы булды. Кемдер милли киемнәрнең тарихы турында сөйләде, кемдер татар мәкальләре турында, ә бер укучы татарча стикерлар турында эшен тәкъдим итте.
**Айсылу:** Бик кызык. Ә син нәрсә турында сөйләдең?
**Рәшит:** Төрле халыкларның милли бәйрәмнәре турында.
**Айсылу:** Диплом бирделәрме?
**Рәшит:** Әйе, икенче урын алдым.
**[2 секунд пауза]**
**Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

**Алтынчы сорау. Айсылу нинди кыз?**
**Рәшит:** Айсылу, сәлам, бүген өстәмә дәресләрең бармы?
**Айсылу:** Юк, кичә рус теленнән өстәмә дәрес булды. Бүген беркая да барасым юк.
**Рәшит:** Мин дә бүген дәресләрдән соң буш. Әйдә, шәһәр үзәгенә барабыз. Көн шундый матур, җылы, саф һавада йөрербез, “Түбәтәй” кафесына кереп чәй эчәрбез.
**Айсылу:** Мин каршы түгел. Ләкин дәресләрдән соң миңа башта өйгә кайтырга кирәк. Әнием миңа кичке аш пешерергә кушты, чөнки бүген ул эштән соң кайта. Ашарга пешергәч, синең белән үзәккә бара алам. Ничәдә очрашабыз?
**Рәшит:** Кичен шәһәр үзәге тагын да матурррак булыр. Әйдә, кичке алтыда метро янында очрашабыз. Аның белән бару уңайлырак булыр.
**Айсылу:** Яхшы, мин риза. Ә син өйдә әти-әниеңә булышасыңмы?
**Рәшит:** Әлбәттә. Мин, кибеткә барып, ашамлыклар алып кайтам. Ял көннәрендә өй җыештырырга булышам, тузан суртам.
**Айсылу:** Афәрин! Зурларга булышырга кирәк.
**[2 секунд пауза]**
**Прослушайте диалог второй раз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

**Җиденче сорау. Җәйге каникулда Айсылу нишләргә тели?**
**Рәшит:** Айсылу, җәйге каникулда син нишләргә уйлыйсың?
**Айсылу:** Имтиханнардан соң минем эшлисем килә. Хәзер яшүсмерләр өчен шундый мөкинлекләр күп бит.
**Рәшит:** Кем булып эшләргә телисең?
**Айсылу:** Интернет сайтларында яшүсмерләргә төрле эшләр тәкъдим итәләр. Мәсәлән, курьер, официант, флорист булып эшләргә мөмкин.
**Рәшит:** Сиңа кайсы эш күбрәк ошый? Син кайда эшләргә җыенасың?
**Айсылу:** Мин бишенче сыйныфтан алып, ел саен “Сәләт” лагеренда ял иттем. Ә быел шунда әйдаман булып эшләргә җыенам. Анда миңа бик ошый. Шундый кызыклы чаралар оештыралар. Бөтен балалар рәхәтләнеп катнаша. Ә июль аенда Биләрдә фестиваль үтә, анда барлык лагерьлардан балалар җыела.
**Рәшит:** Әйе, бу лагерь турында укыганым бар. Мин җәйне күбрәк авылда үткәрәм. Әби белән бабам Арча районында яшиләр. Мин аларда ял итәм, шуңа күрә лагерьга барганым юк. Ә сиңа, Айсылу, уңышлар телим. Җәйге ялың күңелле һәм файдалы үтсен, эшләрең уңышлы булсын.
**Айсылу:** Рәхмәт! Сиңа да иң яхшы теләкләр. Ялларыбыз яхшы үзсын!

**[2 секунд пауза]**
**Прослушайте диалог второй раз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

***Прослушайте разговор двух друзей. Определите, какие из приведенных утверждений 8 - 13 соответствуют содержанию текста, а какие – не соответствуют. Вы услышите аудиозапись дважды.***

**[пауза 20 секунд]**

Самат: Сәлам, Алсу!
Алсу: Сәлам, Самат! Туган көнең белән сине! Сиңа сәламәтлек, шатлык, бәхет, имтиханнарда уңышлар телим!
Самат: Бик зур рәхмәт, Алсу.
Алсу: Туган көн бәйрәмен бүген үткәрәсеңме?
Самат: Бүген гаиләбез белән билгеләп үтәбез. Әнием бүген эшләми, ял итә, кичкә бәлеш пешерәм дип әйтте. Әтием эштән кайткач, бергәләп чәй эчәбез, ашыйбыз, аралашабыз.
Алсу: Ә дусларың кайчан котларга җыеналар?
Самат: Алар белән шимбә көнне очрашабыз. Мин аларны Бауман урамындагы бер кафега чакырам. Сине дә бәйрәмдә көтәм. Без бит – дуслар!
Алсу: Чакыруың өчен зур рәхмәт! Кызганыч, мин туган көнеңдә була алмыйм, чөнки бу көнне әбиемнең юбилеен үткәрәбез.

Самат: Менә сиңа мә! Син булырсың дип ышанган идем. Юбилейны кайда уздырасыз?
Алсу: Өйдә. Әнием белән табын әзерлибез, тәмле ризыклар пешерәбез, туганнарны бәйрәмгә чакырабыз.
Самат: Туганнарыгыз күпме?
Алсу: Күп. Мамадыштан, Арчадан, Самарадан туганнарыбыз килергә җыена.
Самат: Әбиеңә бүләк әзерләдеңме инде? Аңа нәрсә бүләк итәргә уйлыйсың?
Алсу: Әйе, әнием белән без аңа бик матур ак мамык шәл алдык. Әбиемә бик килешер дип уйлыйм.
Самат: Яхшы бүләк сайлагансыз. Минем әбием дә ак мамык шәл бәйләргә ярата.
Алсу: Сиңа да, дустым, бүләк әзерләдем. Беләсеңме нәрсә?
Самат: Шулаймыни? Юк, белмим.
Алсу: Әйдә, уйлап кара әле, бу нәрсә булырга мөмкин? Китапмы? Өстәл уенымы? Футбол тубымы? Син бит футбол белән шөгыльләнәсең.
Самат: Бик кызык сорау бирдең син миңа! Нәрсә әйтергә дә белмим.
Алсу: Әйе шул. Бик авыр сорау. Мин сиңа татар театрына ике билет бүләк итәм. Теләсәң, әниең белән барырсыз, теләсәң, әбиең белән. Анда хәзер бик кызыклы спектакль бара. Аның исеме – “Рәшә”. Ул танылган татар язучысы Әмирхан Еники повесте буенча куелган. Без әнием белән карадык. Безгә ошады.
Самат: Шәп бүләк, дустым! Син мине сөендердең. Футбол белән шөгыльләнсәм дә, театрга йөрергә дә бик яратам.
Алсу: Беләм инде, шуңа күрә шундый бүләк алдым.
**[2 секунд пауза]**
**Прослушайте диалог второй раз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

**Внесите ответы в бланк ответов.**

## Татар теле буенча имтихан эшен бәяләү системасы

1-28 нче биремнәрдә дөрес күрсәтелгән һәр җавап 1 балл белән бәяләнә. Җаваплар биремнәрне үтәү күрсәтмәсендәгечә язылган булса һәм дөрес җавап үрнәге белән тулысынча туры килсә, бирем дөрес үтәлгән дип санала.

**ҖАВАПЛАР**

| **Биремнең номеры** | **Дөрес җавап** |
|---|---|
| 1 | 3 |
| 2 | 2 |
| 3 | 3 |
| 4 | 1 |
| 5 | 3 |
| 6 | 2 |
| 7 | 3 |
| 8 | 2 |
| 9 | 1 |
| 10 | 1 |
| 11 | 2 |
| 12 | 2 |
| 13 | 1 |
| 14 | 2 |
| 15 | 3 |
| 16 | 1 |
| 17 | 2 |
| 18 | 3 |
| 19 | 2 |
| 20 | 3 |
| 21 | 2 |
| 22 | 3 |
| 23 | 1 |
| 24 | 3 |
| 25 | 2 |
| 26 | 3 |
| 27 | 2 |
| 28 | 2 |

## 29-32 нче биремнәрне бәяләү критерийлары

Сөйләм ситуациясенә караган репликалар язу. 29-32 нче биремнәр максималь 2 балл белән бәяләнә.

*1 нче таблица*

| *№* | *Бәяләү критерийлары* | *Баллар* |
|---|---|---|
| ***I*** | ***Язылган текстның эчтәлеге*** | |
| К1 | Сөйләм ситуациясенә караган репликаны формалаштыру | |
| | Имтихан бирүче, сөйләм ситуациясенә караган репликаны аңлап, җавабын дөрес формалаштырган. Коммуникатив бурыч төгәл үтәлгән.<br>Фактик хаталар юк. | 1 |
| | Имтихан бирүче сөйләм ситуациясенә караган репликаны дөрес формалаштырмаган.<br>***Яки*** Сөйләм ситуациясенә караган реплика өлешчә генә формалаштырылган<br>***Яки*** дөрес формалаштырмаган.<br>***Яки*** Фактик хаталар бар.<br>***Яки*** Имтихан **бирүче башка сөйләм ситуациясенә караган реплика язган**. | 0 |
| ***II*** | ***Грамоталылык*** | |
| К2 | Орфография һәм сөйләм нормаларының үтәлеше | |
| | Репликада орфографиягә тел нормаларының үтәлешенә караган (грамматик, орфографик, стилистик. пунктуацион) хаталар юк.<br>***Һәм/ яки*** төрле нормаларга караган 2 хата бар. | 1 |
| | Репликада тел нормаларының үтәлешенә караган 3 яки күбрәк хата бар.<br>***Яки*** Имтихан **бирүче башка сөйләм ситуациясенә караган реплика язган**. | 0 |
| Язма эш өчен максималь балл | | 2 |

## 33 нче биремне бәяләү критерийлары

## Шәхси хат язу биремен бәяләү критерийлары

*2 нче таблица*

| Критерий | Бәяләү критерийлары | 3 балл | 2 балл | 1 балл | 0 балл |
|---|---|---|---|---|---|
| К1 | Коммуникатив бурычны үтәү | ***Эш тулысынча башкарылган:*** 3 сорауга да тулы җавап бирелгән. Мөрәҗәгать итү, саубуллашу һәм имзалау фразалары дөрес сайланган. Алынган хатка рәхмәт белдерелгән | ***Эш башкарылган:*** 3 сорауга да җавап бирелгән, әмма берсенә бирелгән җавап тулы түгел. Хат стилен бозган 1-2 төгәлсезлек бар ***һәм/яки*** Алынган хатка рәхмәт белдерелмәгән | ***Эш өлешчә башкарылган***: 2 сорауга гомуми җавап бирелгән, әмма 1 сорауга бирелгән җавап тулы түгел ***яки*** бер сорауга гомумән җавап юк. Хат стилен бозган 3 яки күбрәк төгәлсезлек бар, итагатьлелек формалары сакланмаган | ***Эш башкарылмаган:*** 2 сорауга җавап бирелмәгән ***яки*** текстның күләме тулмый |
| К2 | Текстны оештыру | | Текст логик эзлеклелектә төзелгән һәм абзацларга бүленештә хаталар юк; тел чаралары дөрес кулланылган; хатның төзелеше язма этикет нормаларына туры килә | Текст, гомумән алганда, логик эзлеклелектә төзелгән, ләкин логик бәйләнешләрдә ***һәм /яки*** абзацларга бүленештә ***яки*** хатның төзелешендә 1-2 төгәлсезлек бар | Текст төзелешендә логик эзлеклелек сакланмаган; язма текст төзелешендә 3 яки күбрәк хата бар, ***яки*** хатның төзелеше язма этикет нормаларына туры килми. |
| К3 | Текстның лексик-грамматик төзелеше | Коммуникатив бурычны үтәү өчен кирәк булган төрле лексик һәм грамматик чаралар файдаланылган (текстны аңлауга зыян китермәгән 1-2 | Текстны аңлауга зыян китермәгән тел чараларына караган хаталар бар (3-4 тупас булмаган хата рөхсәт ителә) ***яки*** тел хаталары юк, ләкин артык гади | Текстны аңлауга зыян китермәгән тел чараларына караган хаталар бар (5-6 тупас булмаган хата рөхсәт ителә) ***һәм /яки*** текстны аңлауга зыян китерә | Текстны аңлауга зыян китерә торган хаталар 6 дан күбрәк |

| Критерий | Бәяләү критерийлары | 3 балл | 2 балл | 1 балл | 0 балл |
|---|---|---|---|---|---|
| | | төгәлсезлек рөхсәт ителә) | лексик һәм грамматик чаралар кулланылган | торган 1-2 грамматик хата бар | |
| К4 | Орфография һәм пунктуация | | Орфографик һәм пунктуацион хаталар юк, **яки** текст эчтәлеген аңлауга зыян китерми торган 1-2 хата бар | Текст эчтәлеген аңлауга зыян китерми торган 3-4 орфографик һәм пунктуацион хата бар | Текст эчтәлеген аңлауга зыян китерә торган орфографик һәм пунктуацион хаталар 4 тән күбрәк |

Шәхси хат язу биреме К1-К4 критерийлары буенча тикшерелә. Максималь **10 балл** алырга мөмкин.

Текстның эчтәлеге биремгә туры килмәсә (язма хат характерында булмаса, **тәкъдим ителгән сорауларга җавап урынына башка мәгълүмат язылса**, тәкъдим ителгән хат күчереп кенә язылса) бу бирем өчен 0 балл куела.

Хатның күләме 3**0** сүздән ким булса, К3 һәм К4 критерийлары буенча максималь балл куелмый.

Эшнең күләмен билгеләгәндә, беренче сүздән алып соңгысына кадәр (шулай ук адрес, язылу вакыты, имза да) исәпкә алына. **Хатта укучы үзенең чын исемен, адресын күрсәткән очракта эш тикшерелми.**

**Имтихан эше өчен түбәндәге билгеләр куела:**

0 - 12 балл – «2» ле билгесе;

13 - 22 балл – «3» ле билгесе;

23 - 33 балл – «4» ле билгесе. Искәрмә: бу очракта укучының тыңлап аңлау биремнәре өчен (1-13 нче биремнәр) баллары 7 дән кимрәк булмаска тиеш. Әгәр укучының тыңлап аңлау биремнәре өчен баллары 7 дән кимрәк булса, «3» ле билгесе куела.

34 - 46 балл – «5» ле билгесе. Искәрмә: бу очракта укучының тыңлап аңлау биремнәре өчен баллары 10 нан кимрәк булмаска тиеш. Әгәр укучының тыңлап аңлау биремнәре өчен баллары 10 нан кимрәк булса, «4» ле билгесе куела.